

Быел җәйне рәхәтләнеп кvрмәдек тә дияргә була. Башта бик тә эссе булды, ә аннары - салкынча янгырлар кушылды. Бу шартларда урып-җыюны vткәрv җинел тvгел.
Үткән атнада Мордовия Главасы Владимир Волков Рузаевка районында урып-җыю эшләренен барышын тикшерде. Гомумән республика буенча бу конгә 40% тан артык бортеклеләр суктырылган, уртача уныш гектарыннан 24 центнер чамасы тәшкил итә. Бу саннарга Рузаевка аграрийларынын кvрсәткечләре дә якын.
Республика Главасы «АгроК-С» авыл хужалыгы предприятиесе кырларында булды. Шул исәптән Ключарев бистәләре янындагы сыра кайнату арпасын җыю барышын да бәяләде. Авыл хужалыгы предприятиесе директоры Николай Амбаев сойләвенчә, кыр унышы гектардан 28 центнер тәшкил иткән. 200 тоннадан артык сыра кайнату арпасы җыелган, ә тулаем алганда, мен ярым тонна ашлык эшкәртелгән инде. Козге бодай унышы соендерде - гектардан 30 центнердан артык. Әмма кыштан сон, чәчvлекләр тынчу сәбәпле, 800 гектарнын 600 гектарын янадан чәчелде. Шуна һәм язгы һава торышы комачаулаганга, бодай буенча нәтиҗәләр тvбәнрәк булачак. «Быел аграрийлар алдында, терлек-челеккә булган ихтыяҗларны бетерv очен, кимендә, миллион ярым тонна ашлык җитештерv бурычы тора, - дип ассызыклады Мордовия Главасы. - Мона файдаланылмый торган җирләрне авыл хужалыгы әйләнешенә кертеп кенә ирешергә момкин. Бvгенге кондә оешмаларда гына да 66 мен гектар файдаланылмый. Уртача ундырышлылык 30 ц/га булганда, бу мәйданнан остәмә 200 мен тонна ашлык алырга момкин».
Мордовия Республикасы Авыл хужа-лыгы һәм азык-толек министрлыгы саннарына кvз салыйк: Ардатово, Большие Березники, Зубово-Поляна, Инсар һәм башка районнарда козге культураларны чәчvгә керештеләр инде, дип язылa сайтта. 2020 ел унышы очен 180 мен га мәйданда козге культуралар чәчv планлаштырыла. Шулай ук республикада урып-җыю кампаниясе дәвам итә. Республика буенча 19нчы августка барлыгы 210,7 мен га мәйданда бортекле һәм кузаклы культуралар җыеп алынган, 522,7 мен тонна суктырылган, уртача уныш – 24,8 ц/га. Моннан тыш, Мордовия аграрийлары терлек азыгы әзерләvне дәвам итәләр. Авыл хужалыгы терлекләре очен кышка 61,1 мен тонна печән әзерләнгән, ягъни планнын 52 проценты, 534,9 мен тонна сенаж – планлаштырылган кvләмнен 79 проценты. Гомумән алганда, Мордовия Республикасы буенча шартлы терлеккә 15 центнердан артык азык берәмлеге әзерләнгән инде.
Мордовия 2019 елнын гыйнвар-июнь айларында авыл хужалыгы предприятиеләрендә ин кvп сот продуктлылыгы буенча Россия Федера-циясенен 20 тобәге топ - 20нә керде. Кvрсәтелгән чорда Мордовия Республикасында бер сыернын сот продуктлылыгы 3 577

кг, узган елнын шушы чорына карата + 107 кг артык сауганнар. Шулай итеп рейтингта 20нче урындабыз.
Районнарда ничегрәк эш бара икән. Атюрьево районындагы эшләр турында идарәче В.Н.Кучеров район газетасы журналистларына болай сойләгән:
-Урып-жыю эшләре бара. Үзе артыннан тузан оермәсен калдырып тугыз комбайн салмак кына кыр буйлап хәрәкәт итә. Игенченен хезмәте жинел булмавы билгеле, шуна кvрә кулларыннан икмәк исе килгән кешеләргә аерым рәхмәт әйтәсе килә. ООО МАПО «Каменка» игенчеләре яна унышны жыюга 23 июльдә керештеләр. Урып-жыю мәйданнары районда ин зур, шуна кvрә һәр сәгать аяз вакытны югалтмыйча унышны жыярга тырышалар. МАПОда инде берничә дистә ел буе иген басуларын инли торган игенчеләрнен профессиональ оешкан коллективы бар. Әйтергә кирәк, интернациональ команда; татарлар, мордвалар, руслар. Аларнын фамилияләрен атау бик кvнелле. Башка милләтле район кешеләре белән бергә татарларыбыз - Наил Чудин, Рушан Алимбеков ярдәмче Салман Хаников белән, Ринат Абдуршин ярдәмче Сәет Актыкбаев белән, Таһир Әхтәмов тырышып эшлиләр. Житештерv чылбырында ток хужалыгы моһим урынны алып тора, анда яна унышны кабул итvдә Ирадя Дьякова һәм Кадрия Алтышова эшли. Аларнын барысы да кvз алдында, шуна остәп, ботен нәрсәдә намуслылык һәм похтәлек кvренеп тора.
Яна унышны жыеп алу белән бер vк вакытта козге чәчv очен туфракны әзерләv дә бара. Быел иртә таннан карангы тошкәнче «Джон-Дир» тракторларында механизаторлар Сәид Таиров белән Наил Агеев 120-150 гектар мәйданны бер эш сменасында эшкәртәләр. Быел ужымга 3 мен гектар жир бирелә.
Ельник районындагы хәбәрләргә кvз салыйк. АПК һәм шәхси ярдәмче хужалык тармаклары белән эшләv Идарәсенен баш агрономы А.И.Иняев әйтvенчә, район аграрийларынын топ бурычы – янгырларга vч итеп ашлык жыю. Район буенча бортеклеләрне урып-жыю планы 5431 га тәшкил итә, август уртасына 1150 га ужым суктырылган. Ин кvп ашлык суктыру һәм ин югары уныш - Ильич исемендәге хужалык хезмәтчәннәрендә. Биредә 750 га козге бодай суктырылган, уныш - гектарыннан 20 центнер. Икенче урын  «За мир» хужалыгында – гектарыннан 15 центнер уныш белән 345 тонна суктырылган. 10ц/га уныш белән «Молторг» игенчеләре козге арыш жыялар, ә КФХ «Г.А.Крючков» крестьян-фермер хужалыгында - 8 ц/га. Район буенча козге арышнын уртача унышы - 17,3 ц/га. Ильич исемендәге хужалык игенчеләре урып-жыю эшләре белән беррәттән тунга сорvгә дә керешкәннәр, 2140 гектардан 320 гектары кvтәрелгән инде.
Терлекчелек буенча, алынган мәгълv-матларга караганда, районда савылган сот узган ел дәрәжәсен тәшкил итә. Гомуми савым - 30541 кг. Ин кvп сот Ильич исемендәге хужалыгында (тәvлегенә 11439 кг), һәр сыердан 17,2 кг сот савыла. Салкын жәй сот житештерvдә унайсызлыклар тудырды һәм «П.Н.Овчинников» хужалыгында ин зур минус - 4,7 кг.
Димәк, жәйнен салкынына карамастан, унай һәм тискәре нәтижәләр бар. Кыр һәм ферма хезмәткәрләре унай нәтижә очен системалы эш алып бара. Бу печән әзерләгәндә берничә кон кояшта йокламаучыларга да, вакытында чәчкән кукурузны эшкәртvчеләргә дә кагылды. Жәйнен сонгы атналары һәм сентябрь башы жылы булса, кукуруздан шактый яхшы уныш алырга тиешбез, ди авыл хужалыгы белгечләре.

**Наилә Насырова**